# Тере организмнарның билгеләре

76. Тере организмдагы химик реакция тизлегенең температурага бәйле булуын күрсәткән графикны өйрәнегез ($x$ күчәре – организмнарның температурасы, ә $y$ күчәрендә – химик реакциянең чагыштырмача тизлеге (шартлы берәмлекләрдә)).




Күрсәтелгән температура диапазонында бу бәйлелекне түбәндә китерелгән тасвирлауларның кайсы төгәлрәк характерлый? Температура арту белән тере организмда химик реакцияләрнең тизлеге нишли?

1) график дәвамында әкренләп үсә

2) кисәк түбәнәя, үзенең минималь күрсәткеченә җитә, аннан соң кисәк арта

3) әкренләп үсә, үзенең максималь күрсәткеченә җитә, аннан соң әкрен генә кими

4) уртача күрсәткечләр янәшәсендә салмак кына тирбәлә

77. Түбәндә бирелгән таблицада беренче һәм икенче баганадагы позицияләр арасында үзара бәйләнеш бар.

| **Термин** | **Нәтиҗә** |
|---|---|
| Табигый сайланыш | Организмнарның күптөрлелеге |
| Мутацияләр | … |

Таблицада төшеп калган урынга нинди төшенчәне язарга кирәк?

1) тирәлекнең шартлары үзгәрү

2) генотипның үзгәреше

3) матдәләр алмашына сәләтле булу

4) үрчүгә сәләтле булу

78. Фотосинтезның чагыштырмача тизлеге белән углекислый газ концентрациясе арасында бәйлелекне күрсәткән графикны өйрәнегез (*x* күчәрендә – углекислый газның концентрациясе (%ларда), ә *y* күчәрендә – фотосинтезның чагыштырмача тизлеге (шартлы берәмлекләрдә)).




0,01 – 0,06 интервалында углекислый газ концентрациясе бәйлелеген түбәндә тәкъдим ителгән тасвирламаларның кайсы төгәлрәк күрсәтә? Бу интервалда фотосинтезның тизлеге ...

1) график дәвамында әкренләп үсә

2) үзгәрешсез кала

3) башта кисәк үсә, аннары үзгәрешсез кала

4) график дәвамында кими

79. Түбәндә бирелгән таблицада беренче һәм икенче баганадагы позицияләр арасында үзара бәйләнеш бар.

| **Бөтен** | **Өлеш** |
|---|---|
| Күкәйлек | … |
| Бөер | Бөер тәңкәсе |

Таблицада төшеп калган урынга нинди төшенчәне язарга кирәк?

1) яралгы

2) күкәй күзәнәк

3) организм

4) зигота

80. Түбәндә бирелгән таблицада беренче һәм икенче баганадагы позицияләр арасында үзара бәйләнеш бар.

| **Объект** | **Процесс** |
|---|---|
| … | Күзәнәк эчендәге ашкайнату |
| Вакуоль | Туклыклы матдәләрне саклау |

Таблицада төшеп калган урынга нинди төшенчәне язарга кирәк?

1) хромопласт

2) ЭПС

3) Гольджи комплексы

4) лизосома

81. Энергия алмашы кайда бара?

1) төштә

2) хлоропластларда

3) митохондриядә

4) вакуольдә

82. Хайваннарның тереклек эшчәнлеге турында түбәндәге фикерләр дөресме?

А. Кыскара торган иң гади вакуольләрдә эшкәртелмәгән азык калдыклары туплана һәм алар тышкы тирәлеккә чыгарыла.

Б. Иң түбән төзелешлеләрдә азык кисәкләре янында ашкайнату вакуольләре барлыкка килә.

1) А гына дөрес

2) Б гына дөрес

3) ике фикер дә дөрес

4) ике фикер дә дөрес түгел

83. Түбәндә бирелгән таблицада беренче һәм икенче баганадагы позицияләр арасында үзара бәйләнеш бар.

| **Бөтен** | **Өлеш** |
|---|---|
| Крахмал | Глюкоза |
| РНК | … |

Таблицада төшеп калган урынга нинди төшенчәне язарга кирәк?

1) аминокислота

2) фруктоза

3) целлюлоза

4) нуклеотид

84. Кешенең мускул тукымасы үзлекләре турында түбәндәге фикерләр дөресме?

А. Мускул тукымасының иң төп үзлеге – ул ярсынучанлык һәм үткәрүчәнлек.

Б. Кан тамырларының, эчәклек, сидек куыгы стеналары аркылы-буйлы мускул тукымасыннан төзелгән.

1) А гына дөрес

2) Б гына дөрес

3) ике фикер дә дөрес

4) ике фикер дә дөрес түгел

85. Нәрсә бары тик чит организмда гына тере система билгеләрен күрсәтә?

1) туберкулез таякчыгы

2) тайга талпаны

3) чәчәк (оспа) вирусы

4) бавыр имгеч суалчан (печёночный сосальщик)

86. Күрсәтелгән процессларның кайсы күзәнәкләрдә энергия барлыкка килүдә (АТФ) белән бәйләнгән?

1) аксым биосинтезы

2) ДНКның икеләтә арта алуы

3) әчү

4) күзәнәкнең бүленүе

87. Ни өчен су җитмәгәндә үсемлек шиңә башлый?

1) күзәнәк согының күзәнәк вакуоле тышчасына басымы кими

2) үсемлеккә минераль тозлар җитми

3) үсүгә тәэсир итә торган гормоннар концентрациясе кими

4) фотосинтез активлыгы кими

88. Рәсемдә күрсәтелгән күзәнәк структурасын ничек атыйлар? 

1) төш

2) вакуоль

3) лизосома

4) митохондрия

89. Күзәнәктә нәселдәнлек турында мәгълүматны җиткерү һәм саклау функциясен нинди молекулалар үти?

1) майлар

2) ДНК

3) углеводлар

4) аксымнар

90. Санап кителгән галимнәрнең кайсын эволюция турында тәгълиматка нигез салучы дип саныйлар?

1) И.И. Мечников
2) Л. Пастер
3) Ч. Дарвин
4) И.П. Павлов

91. Нинди система категориясе иң кечесе булып санала?

1) патшалык
2) класс
3) ыруг
4) төр

92. Җир планетасында яшәүче барлык организмнар нәрсәгә ия?

1) күзәнәкләрнең бертөрле төзелешенә
2) күзәнәкләрнең бертөрле химик составы
3) бер үк органоидларга
4) бертөрле генетик кодка

93. Нинди химик элемент күзәнәкнең яшәеше өчен мөһим булган органик кушылмалар составына керә?

1) фтор
2) калий
3) углерод
4) бакыр

94. Әгәр бабасының кан лейкоцитларында 46 хромосома булса, аның оныгының күзәнәкләрендә ничә хромосома булачак?

1) 0

**2)** 23

**3)** 46

**4)** 92

95. Рәсемдә сурәтләнгән күзәнәк структурасының функциясе нинди?

**1)** аксымны биосинтезлау

**2)** крахмалны синтезлау

**3)** тышкы тәэсир итүләрдән саклану

**4)** генетик мәгълүматны саклау



96. Нинди химик кушылма ДНК мономеры булып тора?

**1)** глюкоза

**2)** аминокислота

**3)** глицерин

**4)** нуклеотид

97. Ген – ул ... молекуласының бер өлеше.

**1)** аксым

**2)** ДНК

**3)** РНК

**4)** АТФ

98. Имән күзәнәге һәм кешенең мускул күзәнәге охшаш ... ия.

**1)** туклану тибына

**2)** запас матдәләргә

**3)** күзәнәк тышчасының составына

**4)** генетик кодка

99. Кешенең иммун системасын юкка чыгара торган  вирус – ... .

**1)** СПИД

**2)** су чәчәге (ветрянка)

**3)** бума ютәл (коклюш)

**4)** грипп

100. Нинди организмнарның күзәнәк тышчасы целлюлозадан тора?

**1)** 

**2)** 

**3)** 

**4)** 

101. Рәсемдә үсемлек күзәнәге сурәтләнгән. А хәрефе белән билгеләнгән күзәнәк өлеше нинди функция башкара?

**1)** туклыклы матдәләр җитештерә

**2)** тереклек эшчәнлеген контрольдә тота

**3)** кояш энергиясен йота

**4)** суны саклый




102. Маратка үсемлек күзәнәгенең төзелешен өйрәнергә кирәк. Тикшеренүне уңышлы башкарып чыгу өчен аңа 200 тапкыр зурайта (×200) торган микроскоп кирәк. Аның 20 тапкыр зурайта торган (×20) объективы бар. Аңа күпмегә зурайта торган окуляр кирәк?

**1)** ×4000

**2)** ×220

3) ×180

4) ×10

103. Күзәнәк структурасының кайсы функциясе хайваннардагы тире катламы функциясе белән охшаш?

1) төш

2) лизосома

3) ЭПС

4) күзәнәк мембранасы

104. Кайсы галим, беренчеләрдән булып, бөке агачының юка кисемендә күзәнәкләр күрә һәм беренче тапкыр «күзәнәк» терминын куллана?

1) Р. Гук

2) И.П. Павлов

3) Г. Мендель

4) Н.И. Вавилов

105. Күзәнәк теориясенең асылы түбәндәге нигезләмәдә чагыла:

1) үзләренең функцияләре буенча барлык организмнарның күзәнәкләре охшаш

2) барлык организмнарның күзәнәкләрендә төш була

3) барлык организмнар күзәнәктән тора

4) хайваннар һәм үсемлекләр генә күзәнәкләрдән тора

106. XIX гасыр уртасында күзәнәк теориясе барлыкка килү ... үсеше белән бәйле.

1) генетика

2) медицина

3) микроскопия

4) эволюция теориясе

107. Нинди организмнарның күзәнәкләре үзләренең составларында тыгыз тышча, бөҗралы ДНК, рибосома һәм плазматик мембранага ия?

1) үсемлекләр
2) бактерияләр
3) гөмбәләр
4) хайваннар

108. Рәсемдә сурәтләнгән органоид ничек атала?

1) митохондрия
2) рибосома
3) хлоропласт
4) төш



109. Күзәнәкнең чагыштырмача даими химик составы нәрсә ярдәмендә саклана?

1) матдәләр алмашы
2) бүленү
3) үсү
4) җитлегү

110. Рәсемдә хлоропласт сурәтләнгән, моны ... булудан белеп була.

**1)** кристлар

**2)** куышлык һәм цистерн

**3)** граналар

**4)** төшчек



111. Үсемлек, гөмбә, бактерия күзәнәкләренең тыгыз тышчасы нинди функцияне үти?

**1)** көйләгеч

**2)** сигнал

**3)** саклагыч

**4)** терәк

112. Эчке мембранада күп җыерчыклар булган органоид ул – ...

**1)** митохондрия

**2)** Гольджи комплексы

**3)** эндоплазматик челтәр

**4)** рибосома

113. Тере организмнарга, терек булмаган табигатьтән аермалы буларак, ... хас.

**1)** үсү

**2)** хәрәкәт

**3)** ярсучанлык

**4)** ритмлылык

114. Нинди хайван аэроб шартларда тереклек итә?

1) үгез тасма суалчаны (бычий цепень)

2) яңгыр суалчаны

3) таран үләне (острица)

4) аскарида

115. Түбәндәге систематик группаларның кайсы төре арасында иң аз охшашлык күзәтелә?

1) патшалык

2) тип

3) класс

4) отряд

116. Теплицада кыяр уңышын арттыру өчен нишләргә кирәк?

1) аларга сирәгрәк су сибәргә

2) бертуктаусыз үсентене тирәсен казып торырга

3) һавада углекислый газның күләмен арттырырга

4) анда яктылыкны киметергә

117. Нинди рәсем астында үсемлек кебек тә, хайван кебек тә тукланучы беркүзәнәкле организм сурәтләнгән?

1) 

**2)** 

**3)** 

**4)** 

118. Фотосинтез процессында нинди матдә барлыкка килә?

**1)** углекислый газ

**2)** аксым

**3)** су

**4)** глюкоза

119. Туфракны йомшарту, үсемлекнең төбен өю ни өчен кирәк?

1) аларның тамыр үсешен яхшырту өчен
2) чәчәк ату тизрәк башлансын өчен
3) фотосинтезның интенсивлыгын арттыру
4) үсемлекне корткычлардан саклау өчен

120. Рәсемдә бүлмә үсемлекләре үрчетүнең нинди алымы күрсәтелгән?

1) кустны аерып үрчетү
2) сабактан үрчетү
3) яфрак сабакчасыннан үрчетү
4) тамырдан үрчетү



121. Прокариотик һәм эукариотик организмның күпчелек күзәнәкләре өчен төп билге булып ... булу тора.

1) формалашкан төш
2) хлоропластлар
3) митохондрия
4) нәселдәнлек аппараты

122. Башка организмнарның күзәнәкләрендә нәрсә үрчи?

1) фагоцит
2) вирус
3) лимфоцит

4) тромбоцит

123. Терек табигать патшалыгының кайсы төрендә тоташтыргыч тукыма бар?

1) Хайваннар
2) Үсемлекләр
3) Бактерияләр
4) Гөмбәләр

124. Барлык организмнар да нәрсәгә сәләтле?

1) сулау, туклану, үрчүгә
2) пространствода актив күченеп йөрүгә
3) неорганиктан органик матдәләр барлыкка килүгә
4) туфрактан суда эрегән минераль матдәләрне үзләштерүгә

125. Хлорофилл молекулалары нинди функцияне үти?

1) яктылык квантын йота
2) күзәнәкләргә углекислый газ алып бара
3) күзәнәкләргә кислород алып бара
4) химик бәйләнеш энергиясен җылылыкка әйләндерә

126. «Төш организмы» терминына нинди термин синоним була ала?

1) беркүзәнәкле
2) эукариот
3) прокариот
4) иң түбән төзелешлеләр

127. Кайсы төшенчәләр эзлеклелеге, бердәм система буларак, организмны чагылдыра?

1) Орган – тукыма – организм – күзәнәк – молекула – органнар системасы
2) Молекула – тукыма – күзәнәк– орган – органнар системасы – организм

3) Молекула – күзәнәк – тукыма – орган – органнар системасы – организм
4) Органнар системасы– орган – тукыма – молекула – күзәнәк– организм

128. Билгеләр нәселдән килә яки аларга тормыш дәвамында барлыкка киләләр. Түбәндәге билгеләрнең кайсы тормыш дәвамында барлыкка килгән?

1) умыртка саны
2) күзнең төсе
3) кан группасы
4) тәндәге яра эзе

129. Сөяк тукымасы ул ... тукыма төре булып санала.

1) эпителиаль
2) мускул
3) тоташтыргыч
4) нерв

130. Сулау процессында үсемлекләр нинди газ йоталар?

1) озон
2) азот
3) кислород
4) углекислый газ

131. Барлык үсемлекләрнең – суүсемнәрдән башлап, ябык орлыклыларга (чәчәкле) кадәр –
... була.

1) күзәнәк
2) тукыма
3) вегетатив органнары
4) генератив органнары

132. Үсемлекләр нинди процесс вакытында кислород бүлеп чыгаралар?

1) фотосинтез
2) сулау
3) парга әйләнү
4) тамырдан туклану

133. Үзенең гомере буе үсә торган һәм күзәнәкләрендә пластид булмаган, мицелия барлыкка китерә торган организмнар кайсы патшалыкка карый?

1) Үсемлек
2) Бактерия
3) Хайваннар
4) Гөмбәләр

134. Үсемлек күзәнәкләре турында фикерләр дөресме?
А. Бөтен үсемлекләрнең тере күзәнәкләрендә дә вакуольләр була.
Б. Бөтен үсемлекләрнең тере күзәнәкләрендә цитоплазма һәм төш була.

1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) ике фикер дә дөрес
4) ике фикер дә дөрес түгел

135. Хайваннар, үсемлекләрдән аермалы буларак, нинди процесска **сәләтле түгел**?

1) сулау
2) бүлеп чыгару
3) суны парга әйләндерү
4) фотосинтез

136. Санап үтелгәннәрнең кайсы рәсемдә сурәтләнгән?



1) чүпрә күзәнәге
2) эчәк таякчыгы күзәнәге
3) бактериофаг
4) холера вибрионы

137. Санап үтелгәннәрнең кайсы үзгәргән яфрак булып санала? Алты җавап арасыннан өч дөрес җавапны сайлап алыгыз һәм аларның цифрларын күрсәтегез.

1) алманың кабыгы
2) гөләпнең тажы
3) борчакның мыегы
4) чәчәк түшәге
5) кактусның энәсе
6) гөлҗимешнең энәсе

138. Органоидлар һәм алар очрый торган патшалык арасында бәйләнешне билгеләгез. Моның өчен беренче баганадагы һәрбер элементка икенче баганадагы позицияне сайлагыз. Сайлаган җавапларның цифрын таблицага языгыз.

| **ОРГАНОИДЛАР** | **ПАТШАЛЫК** |
|---|---|
| А) центриоль | 1) Хайваннар |
| Б) күзәнәк тышчасы | 2) Үсемлекләр |
| В) үзәк вакуоль | |
| Г) хлоропласт | |
| Д) лейкопласт | |

139. Биологик мембрана составына нәрсә **керми**?

**1)** аксымнар

**2)** липидлар

**3)** углеводлар

**4)** нуклеин кислоталары

140. Нинди организмнар группасы фотосинтезга сәләтле түгел?

**1)** вируслар

**2)** бацилллар

**3)** чүпрә гөмбәчекләр

**4)** цианобактерияләр

141. Реакция барышында фотосинтез тизлегенең температура белән бәйлелеген күрсәткән графикны карагыз. Нинди температурада фотосинтез тизлеге максималь күрсәткечнең 50% тәшкил итәчәк?




**1)** 11

**2)** 14

**3)** 17

**4)** 20

142. Түбәндәге таблица баганаларында күрсәтелгән биологик объектлар һәм процесслар арасында билгеле бер бәйләнеш бар.

| ОБЪЕКТ | ПРОЦЕСС |
|---|---|
| төш | нәселдәнлек турында мәгълүматны саклау |

| | |
|---|---|
| митохондрия | … |

Таблицада төшеп калган урынга нинди төшенчәне язарга кирәк?

1) аксым синтезы
2) күзәнәкнең сулавы
3) фотосинтез
4) углеводларны саклау

143. Фотосинтез турында түбәндәге фикерләр дөресме?
**А.** Фотосинтез бары тик үсемлекләр өчен генә мөһим.
**Б.** Фотосинтез – барлык тере оргнаизмнар өчен органик матдәләр чыганагы.

1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) ике фикер дә дөрес
4) ике фикер дә дөрес түгел

144. Хайван күзәнәгендәге энергия эшләп чыгаручы органоид – ул ...

1) төш
2) лизосома
3) митохондрия
4) рибосома

145. Җенси үрчү турында түбәндәге фикерләр дөресме?
**А.** Хайваннарда бары тик җенси үрчү генә була ала.
**Б.** Үсемлектә җенси үрчү органы булып чәчәк тора.

1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) ике фикер дә дөрес
4) ике фикер дә дөрес түгел

146. Нәрсәләр гетеротроф **булмый**?

1) гөмбәләр
2) хайваннар

**3)** авыру тудыручы бактерияләр

**4)** беркүзәнәкле суүсемнәр

147. Үсемлек күзәнәге составына, гөмбәләрдән аермалы буларак, нәрсә керә?

**1)** төш

**2)** эре үзәк вакуоль

**3)** митохондрияләр

**4)** рибосомалар

148. Түбәндәге таблица баганаларында күрсәтелгән биологик объектлар һәм процесслар арасында билгеле бер бәйләнеш бар. Таблицада төшеп калган урынга нинди төшенчәне язарга кирәк?

| **ОБЪЕКТ** | **ПРОЦЕСС** |
|---|---|
| … | күзәнәкнең сулавы |
| хлоропласт | фотосинтез |

**1)** Гольджи аппараты

**2)** лизосома

**3)** рибосома

**4)** митохондрия

149. Рәсемдә нинди органик матдәнең молекуляр структурасы сурәтләнгән?



**1)** ДНК

**2)** крахмал

**3)** аксым

**4)** АТФ

150. Т-А-Ц-А-Ц-Т/ чылбыры фрагментына комплементар булган ДНК чылбыры фрагментын сайлагыз.

1) У-Т-Г-Т-Г-У
2) А-Т-Г-Т-Г-А
3) Г-Ц-А-Ц-А-Г
4) Ц-У-Т-У-Т-Ц

151. Рәсемдә сурәтләнгән күзәнәк структурасын ничек атыйлар?



1) вакуоль
2) күзәнәк үзәге
3) жгут
4) хромосома

152. Күзәнәкнең нәселдәлек аппараты кайда урнашкан?

1) төштә
2) рибосомада
3) лизосомада
4) Гольджи аппаратында

153. Рәсемдә кайсы молекуланың фрагменты сурәтләнгән?



1) аксым
2) АТФ

3) ДНК

4) РНК

154. Түбәндәге таблицада беренче һәм икенче багана позицияләре арасында бәйләнеш бар.

| **Бөтен** | **Өлеш** |
|---|---|
| аксым | аминокислота |
| РНК | … |

Бу таблицада төшеп калган урынга нинди төшенчәне язарга кирәк?

1) глицерин

2) нуклеотид

3) май кислоталары

4) глюкоза

155. Эпителиаль тукыма нинди функцияне үти? Алты җавап арасыннан өч дөрес җавапны сайлап алыгыз һәм аларның цифрларын күрсәтегез.

1) тире катлавын барлыкка китерә

2) майны туплый

3) эчке органнарның куышлыгына җәелә

4) гәүдәнең хәрәкәтен тәэмин итә

5) секретор функцияне үти

6) организм эшчәнлеген регуляцияли

156. Органик матдәнең төзелеше яки функциясе һәм аларның төрләре арасында бәйләнешне билгеләгез. Моның өчен беренче баганадагы һәрбер элементка икенче баганадагы позицияне сайлагыз. Сайлаган җавапларның цифрын таблицага языгыз.

**ТӨЗЕЛЕШ ЯКИ ФУНКЦИЯ**

А) аминокислота молекулаларының калдыкларыннан тора

Б) биологик катализатор ролен үти

В) һәрвакыт плазматик мембрана матдәсе була

Г) энергиянең төп чыганагы була

Д) үсемлек һәм гөмбәләрнең күзәнәк тышчасы составына керә

Е) антитәнчек булып торалар

**ОРГАНИК МАТДӘ ТӨРЕ**

1) аксымнар

2) углеводлар

157. Күзәнәкнең төзелеше һәм аларның төрләре арасында бәйләнешне билгеләгез. Моның өчен беренче баганадагы һәрбер элементка икенче баганадагы позицияне сайлагыз. Сайлаган җавапларның цифрын таблицага языгыз.

| **<u>КҮЗӘНӘКНЕҢ ТӨЗЕЛЕШЕ</u>** | | **<u>ТӨР</u>** | |
|---|---|---|---|
| **А)** | төш тышчасы булмау | **1)** | прокариотик |
| **Б)** | хромосомалар төштә урнашкан | **2)** | эукариотик |
| **В)** | Гольджи аппараты була | | |
| **Г)** | күзәнәктә бер боҗралы хромосома бар | | |
| **Д)** | АТФ митохондрияләрдә туплана | | |
| **Е)** | җенес хромосомалары юк | | |

158. ДНК молекуласы нуклеотиды составына нәрсә керә?  Алты җавап арасыннан өч дөрес җавапны сайлап алыгыз һәм аларның цифрларын күрсәтегез.

**1)** аденин

**2)** муцин

**3)** гемоглобин

**4)** крахмал

**5)** дезоксирибоза

**6)** фосфор кислотасы

159. Түбәндәге таблицада беренче һәм икенче багана позицияләре арасында бәйләнеш бар.

| **Объект** | **Процесс** |
|---|---|
| … | мәгълүматны саклау |
| күзәнәк үзәге | күзәнәкнең бүленеше |

Бу таблицада төшеп калган урынга нинди төшенчәне язарга кирәк?

**1)** вакуоль

**2)** ЭПС

**3)** рибосома

**4)** төш

160. Тәннең югалган яки зарарланган өлешен яңадан торгызу күренеше ул – ...

**1)** рефлекс

**2)** регенерация

**3)** җенессез үрчү

**4)** личинка барлыкка килү



161. Рәсемдә сурәтләнгән күзәнәк төзелешен ничек атыйлар?

1) митохондрия
2) хлоропласт
3) лизосома
4) төш

162. Нәрсәнең орлыгында май күбрәк?

1) бодайның
2) борчакның
3) укропның
4) көнбагышның

163. Үсемлектә органик матдәләр белән туклану нинди тукымалар ярдәмендә тормышка аша?

1) үзагач
2) үзәк
3) юкәр
4) камбий

164. Нинди матдәләр полисахаридлар була? Өч дөрес җавапны сайлап алыгыз һәм аларның цифрларын күрсәтегез.

1) глюкоза
2) крахмал
3) май
4) балавыз
5) гликоген
6) клетчатка

165. ДНК молекуласыннан аермалы буларак, РНК составында нәрсә бар?

1) моносахарид
2) урацил
3) фосфор кислотасының калдыгы
4) аденин



166. Санап үтелгәннәрнең кайсы рәсемдә сурәтләнгән?

1) эчәк таякчыгы күзәнәге
2) чүпрә гөмбәчеге күзәнәге
3) холера вибрионы
4) грипп вирусы

167. Кешедәге бөтен күзәнәкләр бер күзәнәктән нинди юл белән барлыкка килә?

1) үрчү
2) репликация
3) митоз
4) мейоз

168. Күзәнәкләрендә формалашкан төше булган организмнарга ... карый.

1) ал гөмбә
2) кызамык вирусы
3) печән таякчыгы
4) туберкулез авыруын кузгатучылар

169. Кеше организмындагы төше булган һәрбер күзәнәк нәрсәгә сәләтле?

1) бүленүгә
2) нерв импульсын үткәрү

3) кыскаруга

4) матдәләр алмашына

170. Нинди бактерияләрне «планетаның санитары» дип атыйлар?

1) сөтле әчү

2) черү

3) төерчек

4) уксуслы әчү

171. Башка организмнарның күзәнәкләрендә нәрсә үрчи?

1) фагоцит

2) вирус

3) лимфоцит

4) тромбоцит

172.Үсемлек организмының ныклыгын һәм сыгылмалыгын нәрсә тәэмин итә?

1) төп тукыма

2) механик тукыма

3) үткәргеч тукыма

4) япма тукыма

173. Күгәрек гөмбәләрне кеше кайда куллана?

1) икмәк пешерүдә

2) шәраб ясауда

3) азыкларны силослаганда

4) антибиотиклар ясаганда

174. Бөтен тере организмнар нәрсәдән тора?

1) күзәнәктән

2) тукымадан

3) органнардан

4) органнар системасыннан

175. Түбәндә саналган тукымаларның кайсы хайваннарга карый?

**1)** япма

**2)** үткәргеч

**3)** төп

**4)** нерв